Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлегенең Яңа Аккуҗа торак пунктында **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019ел, 21 ноябрь № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге Яңа Аккуҗа торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. Тәбәрле авыл җирлеге Яңа Аккуҗа авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I группа инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче затлардан, иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш, 2020 елда 350 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Яңа Аккуҗа авылы урамнарын кардан чистарту;
- Сокман авылының Нариман урамына юл салу өчен таш сатып алу, юлга таш җәю һәм тигезләү;
- Сокман авылынын су башнясыннан трассага кадәр суүткәргеч торбаларын алыштыру;
- Сокман авылы өчен пожар гидранты сатып алу һәм аны урнаштыру.

3.Гражданнарның җыен нәтиҗәләрен Тәбәрле авыл җирлеге мәгълүмати стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек Башлыгы М.М.ХАРАСОВ

Совет Табарлинского сельского поселения
Тәбәрле авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002513